РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

# КАРАР

**02 декабрь 2019 ел** **№ 46-2**

## Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслашу максатларында субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга (Кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарның нигезләмәсе, 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, Район бюджетларын төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла..
3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Тәтеш муниципаль районы Башлыгы урынбасары Е.Г. Курковка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Башлыгы** **Р.Х. Сафиуллов**

Тәтеш муниципаль районы
Советының 2019 елның
2 декабрендәге 46-2 номерлы
Карарына
**Кушымта**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслашу максатларында субсидияләр бирү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслашу максатларында бирелә (алга таба – субсидияләр).

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының «Тиешле финанс елына һәм план чорына Тәтеш муниципаль районы бюджеты турында»гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә..

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләренең Төп бүлүчесе - Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы.

4. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бүлү «Тиешле финанс елына һәм план чорына Тәтеш муниципаль районы бюджеты турында»гы Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирүнең максаты һәм тәртибе Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы җирлегкенең Башкарма комитеты арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидияне күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыру сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы җирлегенең Башкарма комитеты субсидия алу өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән срокларда Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетына Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты раслаган форма буенча субсидияләр алуга гариза бирә.

11. I-җирлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә::

$$С_{МТ} = П_i \times У_i \times К_i$$

монда:

$С_{МТ}$ – Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының «Тиешле финанс елына һәм план чорына Тәтеш муниципаль районы бюджеты турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетының керем мөмкинлекләреннән һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләренең чыгым ихтыяҗларыннан чыгып, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;;

$П_i$ – i-җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында финанс ярдәме күрсәтү ихтыяҗы күләме;

$У_i$ – i-җирлекнең Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан чыгым йөкләмәләрен финанслауның иң чик дәрәҗәсе;

$К_i$ – i-җирлек өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының суммар ихтыяҗларын һәм тупланма бюджетының керем мөмкинлекләрен бәяләүдәге аерманың нисбәтенә бәйле рәвештә билгеләнә торган корректлы коэффициент.

12. Субсидияләр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән вакытта ачык булучы территориаль органнары счетларына күчерелә.

13. Субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты кеременә Россия Федерациясе Бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

14. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет

кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты керемена кайтарылырга тиеш.и.

15. Субсидияләрдән максатчан файдалануны тикшереп торуны законнар нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.